КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 26 гыйнвар г.Казань № б-119

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 21 август, б-1882 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 ноябрь, 1533 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 декабрь, б-2951 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы (алга таба – Фонд) һәм Венчурлы инвестицияләү ассоциациясенең түбәндәге тәкъдимнәрен кабул итәргә:

2024 елның 25 – 26 апрелендә Россия венчур форумын (алга таба – Форум) үткәрү турында;

Фондны Форум операторы итеп билгеләү һәм Форум кысаларындагы чараларны оештыру чыгымнарын финанслауны тәэмин итү турында;

«Цифрлы үсешкә ярдәм күрсәтү ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасын Форумның күргәзмә экспозициясен оештыручы һәм Форум кысаларында башка чараларны оештырудашчы итеп билгеләү турында.»;

әлеге боерык белән расланган 2024 елда Россия венчур форумын әзерләү һәм үткәрү буенча республика оештыру комитеты составында:

әлеге комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Фальков Валерий Николаевичны | Россия Федерациясе фән һәм югары белем министры, оештыру комитеты рәисен (килешү буенча) |
| Абдуллаҗанов Эдвард Юныс улын | «Казан дәүләт энергетика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча) |
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызын | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Власов Руслан Игоревичны | «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе директорын |
| Салихов Айдар Рәиф улын | «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе генераль директорын (килешү буенча) |
| Сафин Артем Руслан улын | «Цифрлы үсешкә ярдәм ассоциациясе» коммерциягә карамаган оешмасы директорын (килешү буенча); |

Алексей Валерьевич Песошинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәистәше».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин